**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 февраль № 92

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 6 август, 360 нчы карары белән расланган төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Балтач» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәнең 19 нчы пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 20 апрель, 210 нчы карары белән расланган «Аю урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре сак зонасы режимының 1 нче пункты гамәлен вакытлыча өлешчә туктатып тору хакында

«Ягулык-энергетика комплексы объектлары куркынычсызлыгы турында» 2011 ел, 21 июль, ФЗ-256 нчы Федераль закон нигезендә һәм Холмогоры – Клин магистраль нефть үткәргеченең авариясез эшләвен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елның 1 февраленнән «Ковали КС – Лазарево КС сүс-оптика тапшыру линиясе (ВОЛП). Төзелеш. Беренче этап» проектын тормышка ашыру вакытына алга таба махсус күрсәтмә булганга кадәр түбәндәгеләрнең гамәлен туктатып торырга:

туфрак катламын бозуны, тыюлык эшчәнлегенә бәйле булмаган коммуникацияләр төзүне, гомуми файдаланудагы юллардан тыш автомототранспорт узуны һәм туктап торуны тыю өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Балтач» дәүләт табигать тыюлыгы турында нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 6 август, 360 нчы карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Балтач» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәнең 19 нчы пункты гамәлен;

агачларны һәм куаклыкларны кисү, җирләрне җитештерү билгеләнешендәге объектлар өчен бирү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аю урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәрен оештыру турында» 2001 ел,

20 апрель, 210 нчы карары белән расланган «Аю урманы» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре сак зонасы режимының 1 нче пункты гамәлен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\92.doc